КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 апрель г.Казань № 515

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллегиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2001 ел, 30 июль, 503 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллегиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2001 ел, 30 июль, 503 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 30 декабрь, 604 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «һәм аның составын» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллегиясе турындагы нигезләмәнең 2.1 пунктындагы сигезенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин